ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«19» июля 2021 г. № 103-р

Белем бирү учреждениеләрен
яңа 2021-2022 уку елына әзерләү
һәм кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен яңа 2021-2022 уку елына әзерләүгә бәйле рәвештә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрен яңа 2021-2022 уку елына әзерләү һәм кабул итү буенча район комиссиясенең кушымтада бирелгән составын расларга.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе»нә:

- Террорчылыкка каршы көрәш, янгын һәм санитар-эпидемиологик иминлек кагыйдәләрен үтәүгә аерым игътибар биреп, ведомствога буйсынучы мәгариф учреждениеләрен яңа 2021-2022 уку елы башына һәм кышкы чорда эшләүгә үз вакытында һәм сыйфатлы әзерләүне оештырырга;
- 2021 елның 20, 23 августында "Куркынычсызлык көне" һәр белем бирү учреждениесендә укучыларны һәм персоналны шартлы эвакуацияләү буенча тренировкалар оештыру белән тәэмин итәргә;
- уку елы дәвамында белем бирү учреждениеләрендә укучыларны һәм персоналны шартлы эвакуацияләү буенча күнегүләр үткәрүне тәэмин итәргә;
- гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә мәктәп автобусларында укучыларны ташуның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча барлык кирәкле чараларны күрергә;
- белем алучыларга, мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә ташламалы туклану һәм уку урынына транспортта йөрү өлешендә социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә;
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының авыл җирлекләрендә эшләү өчен югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны педагогик юнәлешле җәлеп итүне тәэмин итә торган шартлар тудыру;

- яңа уку елы башлану мәсьәләләре буенча халык белән мәгълүмати хезмәттәшлек итүне тәэмин итәргә;
- Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге юл баланс тотучылары һәм ЮХИДИ бүлеге белән берлектә мәктәп автобуслары хәрәкәте маршрутлары буенча автомобиль юлларын тикшерергә, юлларны карап тоту һәм эксплуатацияләү торышындагы җитешсезлекләр ачыкланган очракта, 2021 елның 23 августына кадәр юлларны бетерү буенча чаралар күрергә.

3. Әлеге күрсәтмәнең 1 п. белән расланган район комиссиясенә, 2021 елның 20, 23 августында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының яңа 2021-2022 уку елына гомуми белем бирү учреждениеләрен кабул итү эшен төгәлләргә.

4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район комиссиясенә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән берлектә 2021 елның 20, 23 августында «Игътибар - яшүсмер» айлыгы үткәрүне оештырырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**